**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Югары Кәминкә авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегенең**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче Югары Кәминкә авылы, Ибрай Каргалы авылы, Кызыл Яр авылы торак пунктларында

**09 ноябрь 2019 ел** **№ 5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге составына керүче Югары Кәминкә авылы, Ибрай Каргалы авылы, Кызыл Яр авылы торак пунктларында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Югары Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 400 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан тыш.

1. Алынган чараларны җибәрергә:

- Югары Кәминкә, Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- су белән тәэмин итүнең урам челтәрен һәм су башняларын ремонтлау (артезиан скважинасы территориясенең санитар-саклау зонасын төзекләндерү, коймаларны ремонтлау һәм буяу, су башняларын буяу, насосны һәм автоматиканы алыштыру);
- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, трактористка түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнарга;
- ротор чапкыч сатып алуга;
- авыл җирлегенең урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерүгә (вак таш (щебенка) җәю);
- Кызыл Яр торак пунктында зиратны төзекләндерү, агачларны кисү, коймаларны ремонтлау, буяу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга;
- хәбәр итү системасын сатып алу һәм Ибрай Каргалы, Кызыл Яр торак пунктларында урнаштыруга.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Кызыл Яр авылы, Ленин урамы, 13 нче йорт. Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы** **К.М.Гыйләҗев**